**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Поручик авыл җирлегенең Поручик торак пунктында гражданнар җыены үткәрү нәтиҗәләре турында**
**КАРАРЫ**

**20.11.2023** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елның 20 ноябрендә булып узган гражданнар җыены нәтиҗәләре нигезендә сорау буенча беркетмә төзелде: «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Поручик авыл җирлегенең Поручик торак пунктында теркәлгән 18 яшькә җиткән һәр гражданга, I төркем инвалидлардан, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан кала, 2024 елда үзара салымны 500 (биш йөз) күләмендә билгеләргә һәм җыелган сумманы җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотуга сез ризамы:
- алма бакчасы коймалау».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 260 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 165 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен 104 җыенда катнашучы тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен 61 җыенда катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Поручик авыл җирлегенең Поручик торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип санарга.

2. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Поручик авыл җирлегенең Поручик торак пунктында теркәлгән 18 яшькә җиткән һәр гражданга, I төркем инвалидлардан, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан кала, 2024 елда үзара салымны 500 (биш йөз) күләмендә билгеләргә һәм җыелган сумманы җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотуга сез ризамы:
- алма бакчасы коймалау»- сора覆 буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Поручик авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән гражданнар җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә, Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) кабул ителгән көннән 7 көн дәвамында (Поручик авыл җирлеге Уставының 69 п.5 статьясы) урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Поручик авыл җирлеге башлыгы И.И. Хаджаева

СОВЕТ ПОРУЧИКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РТ • ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ПОРУЧИК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ • ИНН 1647003040 КПП 164701001 ОГРН 1021601899175